Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Югары Кондрата авыл җирлеге Советы

Карары

2026 елның 16 феврале №7/2

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Югары Кондрата
авыл җирлеге муниципаль берәмлеге
Советының 05.06.2019 елның 56/1 номерлы
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы «Югары Кондрата авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт
турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 ел, №505-ФЗ Федераль закон нигезендә, Чистай шәһәр прокурорының 26.01.2026 ел, №02-08-2026 Советның 05.06.2019 ел, №56/1 карарына протестын карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Югары Кондрата авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Югары Кондрата авыл җирлеге Советының 05.06.2019 №56/1 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының» Югары Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 13нче маддәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
3 пунктның 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«10) «коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;
5 пунктта «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләрен «гамәлдәге законнарда» сүзләренә алмаштырырга.
2.Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Югары Кондрата
авыл җирлеге башлыгы А.А. Журавлев